**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ**
**СТАРОУТЯМЫШСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

423105,Черемшанский район, с.Старый Утямыш, ул.Мусы Джалиля, дом 52

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ ҮТӘМЕШ АВЫЛ**
**ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

423105,Чирмешән районы Иске Үтәмеш авылы, Муса Җәлил урамы, 52 нче йорт

тел./факс 8-84396-2-37-16 email: Sut.Cmn2@tatar.ru

74 12.12.2022 ел.

Татарстан Республикасы

Чирмешән муниципаль районы Советы

**КАРАРЫ**

2023 елга җирле әһәмияттәге
мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет
ассигнованиеләре бүлеп бирү турында
район Башкарма комитетының
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советына
мөрәҗәгатен карау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Иске Үтәмеш авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 5 декабрендәге 1 номерлы мөрәҗәгатен караганнан соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2023 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге бюджетында бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге башкарма комитеты

мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чирмешән муниципаль районы Иске Үтәмеш авыл җирлеге Советының даими комиссияләренә йөкләргә.

Иске Үтәмеш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.С.Мингулов.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Үтәмеш авыл җирлеге
Советының 2023 елның 12 декабрендәге
74 номерлы карарына
1 нче кушымта

# 2023 елда бюджет ассигнованиеләрен бирү өчен җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр исемлеге

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Иске Үтәмеш авыл җирлеге буенча эчә торган су сыйфатын билгеләнгән таләпләргә туры китерү буенча чаралар планы нигезендә - 4009000 сум. ;

1. Иске Үтәмеш авыл җирлеге буенча зиратлар территориясен дератизацияләү - 80000 сум;
2. «Иске Үтәмеш авыл мәдәният йорты» МБУ объектларын террорчылыкка каршы саклауның суммасы - 975,0 мең сум, шул исәптән (Югары Чегодай авыл мәдәният йорты, Урманасты Үтәмеш авыл мәдәният йорты, Иске Сережкино КФҮ)
3. «Иске Үтәмеш авыл мәдәният йорты» МБУ объектларын янгынга каршы яклау ( пәрдәләрне, сәхнә тартмасын һәм чорма бүлмәләрен янгын сүндерү чаралары белән эшкәртү) - 328,0 мең сум, шул исәптән (Югары Чегодай авыл мәдәният йорты, Урманасты Үтәмеш авыл мәдәният йорты, Иске Сережкино КФҮ)
4. Гидротехник корылмаларны декларация алды тикшерүенә -586,0 мең сум.
5. Шәһәр төзелеше планын эшләү-150000 сум;
6. Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру-150000 сум;
7. Эшчәнлек төренә санитар-эпидемиологик бәяләмә алу-50000 сум;
8. Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту өчен махсус реагентлар сатып алу-5000000 сум;
9. Санкцияләнмәгән чүплекләрне рекультивацияләү-600000 сум;
10. Башка эш төрләре - 15000 сум;
11. Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү-50000 сум;